**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау турында» 2011 елның 12 июлендә имзаланган 158 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау турында» (алга таба – Нигезләмә) 2011 елның 12 июлендә имзаланган 158 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәне «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79-ФЗ номерлы Федераль законга яраклаштыру максатында **боерык бирәм:**

1. Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 3нче пункты «в» подпункты өлешен түбәндәгечә бәян итәргә:

«в) Федераль законның 28нче маддәсенең 2 өлеше, 31нче маддәсенең 1нче өлеше һәм 60.1нче маддәсенең 9нчы өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә»;

Нигезләмәнең 7нче пункты «д» подпункты өлешен түбәндәгечә бәян итәргә:

«д) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм муниципаль хезмәткәрләрен диспансерлаштыру тәртибен, Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәтенә һәм муниципаль хезмәткә урнашырга яисә аны үтәргә каршылык тудыручы авырулар исемлеген, һәм шулай ук медицина учреждениесе бәяләмәсе формасын раслау турында» 2009 елның 14 декабрендә имзаланган 984н

номерлы боерыгы белән расланган дәүләт граждан хезмәтенә урнашырга яисә аны үтәргә каршылык тудыручы авыруларның булмавы турында медицина учреждениесенең 001-ГС/у номерлы формасы буенча тутырылган бәяләмәсе» ;

Нигезләмәнең 20нче пунктының 2нче абзацын түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә белән тулыландырырга:

«Конкурс комиссиясенең граждан хезмәте вазыйфасындагы әгъзалары гына катнашкан утырышын уздыру рөхсәт ителми».

2. Кадрлар һәм кадрлар потенциалы үсеше бүлегенә (В.Р.Садыйкова) әлеге боерыкка Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве уздырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Министр** **М.Р.Шагиәхмәтов**